**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 апрель № 268

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1078 нче, 2014 ел, 22 февраль, 109 нчы, 2014 ел, 24 февраль, 118 нче, 2014 ел, 30 апрель, 284 нче, 2014 ел, 2 июнь, 374 нче, 2014 ел, 17 июнь, 418 нче, 2014 ел, 8 июль, 473 нче, 2014 ел, 9 июль, 477 нче, 2014 ел, 25 август, 612 нче, 2014 ел, 1 октябрь, 709 нчы, 2014 ел, 24 ноябрь, 901 нче, 2014 ел, 6 декабрь, 956 нчы, 2014 ел, 31 декабрь, 1083 нче, 2015 ел, 1 июнь, 390 нчы, 2015 ел, 24 июнь, 459 нчы, 2015 ел, 25 июнь, 460 нчы, 2015 ел, 28 июль, 549 нчы, 2015 ел, 16 октябрь, 770 нче, 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы, 2015 ел, 28 декабрь, 992 нче, 2016 ел, 31 март, 190 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасына (алга таба – Ярдәмче программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Ярдәмче программаның II бүлегендә:

«Ярдәмче программаның төп чаралары сыйфатламасы» бүлекчәсендә утыз тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшьләр эшмәкәрлегенә булышлык күрсәтү:»;

түбәндәге эчтәлекле яңа кырык – кырык сигезенче абзацлар өстәргә:

«яшьләрне эшмәкәрлеккә җәлеп итүгә юнәлгән мәгълүмат кампаниясе үткәрү:

14 – 17 яшьтәге өлкән сыйныфлар өчен уен һәм тренинг чаралары, укыту курслары үткәрү;

бизнес алып бару һәм кече һәм урта предприятиеләр төзү күнекмәләрен алуга юнәлтелгән мәгариф программалары буенча уку максатында эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә сәләтле 30 яшькәчә (30 яшьне кертеп) физик затларны сайлап алу;

бизнес алып бару һәм кече һәм урта предприятиеләр төзү күнекмәләрен алуга юнәлтелгән мәгариф программалары буенча 30 яшькәчә физик затларны укытуны оештыру;

«Россиянең яшь эшмәкәре» бөтенроссия конкурсының төбәк этабын уздыру;

бизнес-проектлар конкурслары уздыру;

яшь эшмәкәрләргә консультация хезмәтләре күрсәтү;

яшьләр эшмәкәрлегенә ярдәм итәргә һәм аны үстерүгә юнәлтелгән төбәкара, гомумроссия һәм халыкара чараларда катнашуны тәэмин итү;

яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итүгә юнәлтелгән нәтиҗәле чаралар мониторингын гамәлгә ашыру.»;

кырыгынчы – кырык бишенче абзацларны туры килү буенча кырык тугызынчы – илле дүртенче абзацлар дип санарга.»;

Ярдәмче программага кушымтаның «Бурыч исеме: КУЭ булышлык күрсәтүнең яңа формаларын булдыру һәм гамәлдәге инфраструктурасын үстерү» бүлегендә:

6 пунктның 12 графасында «3960,00000» саннарын «3884,762000» саннарына алмаштырырга;

14 пунктның 12 графасында «26659,36600» саннарын «25816,248» саннарына алмаштырырга;

16 пунктның 12 графасында «23573,20800»саннарына «18991,56400» саннарына алмаштырырга;

«Бурыч исеме: Икътисадый актив халыкны эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү» бүлегендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1. Яшьләр эшмәкәрлегенә булышлык күрсәтү: Яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итүгә юнәлдерелгән мәгълүмати кампания үткәрү; | ТР ИМ, ТР ЭБФ (килешү буенча) | Дәүләт ярдәме алган КУЭ субъектлары саны, берәмлек | ТРБ/ ФБ | 400 | 18 | - | 1834 | ТРБ | - | - | 5500,0 |
| | | | | | | | | ФБ | - | - | <*> |
| | | Яңа булдырылган эш урыннары | ТРБ/ ФБ | 100 | 25 | - | - | ФБ (акча-ның | 4625,8 <**> | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14 – 17 яшьтәге өлкән сыйныф укучылары өчен уен һәм тренинг чаралар, укыту курслары, конкурслар үткәрү;<br>бизнес алып бару һәм кече һәм урта предприятиеләр төзү күнекмәләрен алуга юнәлтелгән мәгариф программалары буенча уку максатында эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә сәләтле 30 яшькәчә (30 яшьне кертеп) физик затларны сайлап алу;<br>бизнес алып бару һәм кече һәм урта предприятиеләр төзү күнекмәләрен алуга юнәлтелгән мәгариф программалары буенча 30 яшькәчә физик затларны укытуны оештыру;<br>«Россиянең яшь эшмәкәре» бөтенроссия конкурсының төбәк этабын уздыру;<br>бизнес-проектлар конкурслары уздыру;<br>яшь эшмәкәрләргә консультация хезмәтләре күрсәтү;<br>яшьләр эшмәкәрлегенә ярдәм итәргә һәм аны үстерүгә | | саны (яңа теркәлгән шәхси эшмәкәрләрне кертеп), берәмлек | | | | | | файдаланылмаган өлеше) | | | |
| | | Чарада катнашуга җәлеп ителгән 30 яшькәчә кеше саны, кеше | - | - | - | - | 9167 | | | | |
| | | 30 яшькәчә затлар төзегән КУЭ субъектлары саны, берәмлек | | - | - | - | 230». | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| юнәлтелгән төбәкара, гомумроссия һәм халыкара чараларда катнашуны тәэмин итү; яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итүгә юнәлтелгән нәтиҗәле чаралар мониторингын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков